СОВЕТ КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

23.06.2023 д. Канаш _ №27-158

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Канаш авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Канаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик зат вафат булган көннән яисә граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан ителгән көннән соң өч еллык срок узу, әгәр дә варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варисларның берсе дә мирас итеп калдырырга хокуксыз яисә барлык варислар мираска читләштерелгән булса, яки варисларның берсе дә мирасны кабул итмәсә, яки барлык варислар мирастан баш тартса һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын әйтмәсә;

2) салым түләүченең - гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада физик затның булуы;

3) салым салу объекты булган мөлкәткә милек хокукы туктатылган көннән өч ел вакыт узгач;

4) юкка чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү бурычы барлыкка килгән көннән соң өч ел вакыт узгач.

2. Югары Ослан авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2022 елның 20 декабрендәге 22-128 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Канаш авыл җирлеге Башлыгы Н.Н.Вальков